Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль район Советы

**КАРАР№ 138**

Теләче авылы 24 август 2018 ел

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында хәбәр итү Тәртибе турында

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы, 2008 елның 25 октябрендәге “Коррупциягә каршы чаралар күрү турында”гы 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында хәбәр итү Тәртибен расларга (теркәлә).

2.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

2.1)алар карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчеләрен карар белән таныштырырга;

2.2)Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары уставларына, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләренә үзләренең карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчеләренә хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) хәбәр итү бурычларын билгеләүче үзгәрешләрне кертергә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының http://tulachi.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль
районы башлыгы И.Ф.Зарипов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль
район Советының 2018 елның
24 августындагы 138 номерлы
карары белән расланды.

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында хәбәр итү Тәртибе**

1. Тәртип Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында хәбәр итү гамәлен тәртипкә сала.

2. Тәртиптә мәнфәгатьләр низагы төшенчәсеннән вазыйфа (ул мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу һәм көйләү буенча чаралар күрү бурычын күздә тота) алмаштыручы затның (турыдан-туры яки читләтеп) шәхси кызыксынуы вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләрен (вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны) тиешенчә, объектив һәм гадел башкаруга йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вәзгыять аңлашыла.

3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе Россия Федерациясенең коррупциягә каршы чаралар күрү турындагы законнары һәм оешманың (учреждениенең) уставы нигезендә килеп туган мәнфәгатьләр низагы турында хәбәр итәргә һәм шуның белән бергә мәнфәгатьләр низагын булдырмау яки көйләү буенча чаралар күрергә бурычлы.

4.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында аңа билгеле булган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә ) хәбәр итәргә бурычлы.

5. Хезмәт йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән срокта җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә бәйле булмаган сәбәп аркасында хәбәр итү мөмкин булмаганда аны юк иткәннән соң бер эш көненнән дә соңармыйча белдерү хәбәре тапшырыла.

6. Вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакындагы хәбәр язмача формада белдерү хәбәре рәвешендә рәсмиләштерелә (алга таба –

белдерү хәбәре).

Белдерү хәбәрендә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) белдерү хәбәрен тутырган җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

б)җирле үзидарә органы карамагындагы өешма (учреждение) җитәкчесенең (турыдан-туры яки читләтеп) шәхси кызыксынуы хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә, өбъектив һәм гадел башкаруга йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вәзгыятьне тасвирлау;

в) җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан хезмәт йөкләмәләрен тиешенчә башкаруга йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган шәхси кызыксынуны квалификацияләү билгеләре (җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе һәм (яки) аның белән якын туганлыкта яки якынлыкта булган затлар (ата-аналары, ирләре, хатыннары, балалары, энеләре, сеңелләре, шулай ук ирләренең (хатыннарының) энеләре, сеңелләре, ата-аналары, балалары, балаларының ирләре (хатыннары)), җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе белән һәм (яки) аның белән якын туганлыкта яки якынлыкта булган затлар милек, корпоротив яки башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән граждaннар һәм оешмалар тарафыннан акча, башка милек, шул исәптән милек хокуклары, мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яки нинди дә булса файдалар (өстенлекләр) рәвешендә керем алу мөмкинлекләре);

г) шәхси кызыксынуның аларны башкаруга тискәре йогынты ясарга мөмкин булган яки тискәре йогынты ясаучы хезмәт йөкләмәләрен тасвирлау;

д) мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү мөмкинлеген булдырмый калырлык яки барлыкка килгән мәнфәгатьләр низагын көйләрдәй мөмкин булганча тәкъдим ителүче чаралар;

е) белдерү хәбәрен тутыру датасы;

ж) белдерү хәбәрен тутыручы затның имзасы.

7.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) 1 номерлы кушымтага ярашлы формада төзелгән белдерү хәбәре җибәрә.

8.Эш бирүче (яллаучы вәкиле) адресына килгән белдерү хәбәрләре карау өчен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында хезмәт (вазыйфа) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр низагын көйләүгә куелган таләпләрне үтәү буенча комиссиягә тапшырыла.

9.Белдерү хәбәрләрен теркәү Комиссия сәркатибе тарафыннан белдерү хәбәрләрен теркәү журналында гамәлгә ашырыла (журналның киңәш, тәкъдим ителә торган үрнәге Тәртипнең 2 номерлы кушымтасында каралган).

Комиссия сәркатибе белдерү хәбәрендәге хәбәрнең яшеренлеген сакларга бурычлы.Яшерен хәбәрне таратуда гаепле зат дисциплинар, Россия Федерациясе законнары нигезендә башка җаваплылык күрә.

10. Белдерү хәбәренең копиясе теркәү турындагы билге белән Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы

оешма (учреждение) җитәкчесе кулына белдерү хәбәрләре журналында кул куйдырып бирә яки алу турында белдерү хәбәре белән почта аша җибәрә.

11. Белдерү хәбәрләрен алдан карау барышында Комиссия белдерү хәбәрен җибәргән затлардан тиешле тәртиптә аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм тиешле тәртиптә дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә хокуклы.

12.Белдерү хәбәрләрен алдан карау йомгаклары буенча һәркайсына дәлилле нәтиҗә әзерләнә.

Белдерү хәбәрләрен алдан карау барышында алынган белдерү хәбәрләре,нәтиҗәләр һәм башка материаллар Комиссия утырышына белдерү хәбәрләре кергән коннән соң җиде эш көне эчендә тәкъдим ителә.

Тәртипнец 11 пунктында күрсәтелгән запрослар җибәрү очрагында белдерү хәбәрләре, нәтиҗәләр һәм башка материаллар Комиссиягә эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) белдерү хәбәрләре кергән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, тик 30 көннән артыкка түгел.

13. Комиссия Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2018 елның 24 августындагы " Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәүһәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссия хакындагы Нигезләмәне раслау турында"гы 137 номерлы карары белән расланган комиссия турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә белдерү хәбәрләрен карый һәм алар буенча карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) җибәрә.

14. Эш бирүче (яллаучы вәкиле) Комиссия тарафыннан белдерү хәбәрләрен карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а)белдерү хәбәрен җибәргән зат тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр низагы булмауны танырга;

б) белдерү хәбәрен җибәргән зат тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр низагына китерә яки китерергә мөмкин икәнлекне танырга;

в) белдерү хәбәрен җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм (яки) көйләү буенча чаралар үтәлмәүне танырга.

15. Тәртипнең 14 пункты "б" пунктчасында каралган карарны кабул итү очрагында Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе Россия Федерациясе законнары нигезендә мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм (яки) көйләү буенча чаралар күрә яки чаралар күрүне тәэмин итә.

16. Тәртипнең 14 пункты "в" пунктчасында каралган карарны кабул итү очрагында Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә карата Россия Федерациясенең Хезмәт кодексында, җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) уставы һәм хезмәт шартнамәсендә каралган дисциплинар җәзалар кулланыла.

Белдерү хәбәрен карау белән бәйле белдерү хәбәре һәм башка материаллар Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең шәхси делосына теркәлә.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында хәбәр итү Тәртибенә
1 номерлы кушымта

Тәкъдим ителүче үрнәк

______________________________

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУ башлыгы, "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге" МКУ башлыгы, ""Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге"МКУ башлыгы (тиешлесен сайларга)

______________________________
(Ф.И.О.)
______________________________дан
(Ф.И.О.,вазыйфа)

**вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында**
**БЕЛДЕРҮ ХӘБӘРЕ**

Миндә вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында хәбәр итәм (кирәклесенең астына сызарга).
шәхси кызыксынуның барлыкка килүенә нигез булган хәлләр:

______________________________________________________________

шәхси кызыксыну йогынты ясый торган яки йогынты ясарга мөмкин булган вазыйфаи йөкләмәләр: : ______________________________________

______________________________________________________________

мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм (яки) көйләү буенча тәкъдим ителә торган чаралар:

______________________________________________________________

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи)

тәртибенә куелган таләпләрне үтәү буенча Комиссия утырышында белдерү хәбәрен караганда шәхсән катнашу ниятем бар (ниятем юк) (кирәклесенең астына сызарга)

“__” ________ 20__ ел. _______________________________ ________________________
(белдерү хәбәрен җибәргән затны имзасы (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында хәбәр итү Тәртибенә 2 номерлы кушымта

Тәкъдим ителүче үрнәк

**Эш бирүченең (яллаучы вәкиленең) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе хакында җибәрелгән белдерү хәбәрләрен теркәү журналы**

| № п/п | Белдерү хәбәрен теркәү номеры | Белдерү хәбәрен теркәү датасы | Белдерү хәбәре тәкъдим ителде | | Белдерү хәбәре теркәлде | | | Белдерү хәбәренең копиясен алу турында билге (копияне алдым, имза) яки белдерү хәбәренең копиясен почта аша җибәрү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ф.И.О. | вазыйфа | Ф.И.О. | вазыйфа | имза | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

______________________